**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Учаллинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авылы**
**җирлеге башкарма комитеты**

ул. Советская, д. 51, село Учалле,
Азнакаевского муниципального
района, 423317

Совет урамы, 51, Үчәлле авылы
Азнакай муниципаль районы
423317

Тел./факс(885592)36-8-32; E-mail:Uchal.Azn@tatar.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №31

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Үчәлле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 200 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш җәю (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү): Якты Күл авылы Якты Күл урамына;
- вак таш җәелгән юлларда чокырлар ямау (ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү): Үчәлле авылы Совет, Октябрь, Тукай урамнарында, Якты Күл авылы Якты Күл урамында, Текмәле авылы Ишкәй урамында, Кызыл Йолдыз авылына керү юлында;
- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен тракторчы булган техниканы арендалау;
- Үчәлле, Текмәле, Якты Күл, Кызыл Йолдыз авылларын куаклардан, чүп үләннәреннән чистарту һәм тоташ гербицид белән химик эшкәртү ;
- Үчәлле, Текмәле, Якты Күл, Кызыл Йолдыз авыллары юлларын кардан чистарту;

- җәйге вакытта Үчәлле, Текмәле, Якты Күл, Кызыл Йолдыз авыллары территорияләрен чабу;

- Үчәлле авыл җирлеге территориясенү кергән авылларда бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү, бүләк, сувенир продукциясе сатып алу («Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел»);

- Үчәлле, Текмәле, Якты Күл, Кызыл Йолдыз авылларындагы урам утларын, яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- җирлек территориясендә чүп үләнен чабу өчен триммерлар, запас частьләр һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу;

-Үчәлле, Якты- Күл, Текмәле, Кызыл Йолдыз авылларында ике телдә урам күрсәткечләрен һәм торак йортлар өчен номерлар сатып алу (ясау);

-Якты Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы кору (материал сатып алу һәм килешү буенча эш өчен түләү);

- Үчәлле авылында сугышта һәлак булган сугышчылар истәлегенә куелган һәйкәлне ремонтлау (коймалар алыштыру, ветераннар исемлеген яңарту, килешү буенча эш өчен түләү), Үчәлле, Якты Күл авылларындагы Бөек Ватан сугышы ветераннары стендын ясау.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

-Россия,Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Үчәлле авылы, Совет ур., 51 йорт;

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты Күл авылы. Якты Күл, 15 йорт;

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Текмәле авылы, Ишкәй урамы, 15 йорт;

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Кызыл Йолдыз авылы, ул. Кызыл Йолдыз урамы,2 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык Г.М.Төхвәтуллина